КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 30 декабрь г.Казань № 1142

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 – 2022 елларда Татарстан Республикасында «Уңайлы шәһәр мохиты формалаштыру» өстенлекле проектын тормышка ашыру чаралары турында» 2017 ел, 21 сентябрь, 706 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Заманча шәһәр мохитын формалаштыруның Россия Федерациясе субъектларының дәүләт программаларына һәм муниципаль программаларга булышлык күрсәтергә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 ел, 10 февраль, 169 нчы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 – 2022 елларда Татарстан Республикасында «Уңайлы шәһәр мохиты формалаштыру» өстенлекле проектын тормышка ашыру чаралары турында» 2017 ел, 21 сентябрь, 706 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Төзекләндерелергә тиеш җәмәгать территорияләрен сайлап алу буенча тавыш бирү оештыру һәм үткәрү тәртибе»;

әлеге карарга Төзекләндерелергә тиеш җәмәгать территорияләрен сайлап алу буенча тавыш бирү оештыру һәм үткәрү тәртибен өстәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин